# 1990 елның 4 марты—халык депутатларын сайлаулар көне

## 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидат

## Петр Алексеевич ТИМИРЯСОВ



Петр Алексеевич Тимирясов 1955 елда Первомай районының Багана поселогында туган. Милләте буенча чуваш. КПСС члены.

Хезмәт эшчәнлеген Новоильмово урта мәктәбен тәмамлагач, Чирмешән районының Ворошилов исемендәге колхоз колхозчысы булып башлый. 1973 елдан 1975 елгача Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Армиядән соң Алабуга педагогия институтының гомумтехник дисциплиналар һәм хезмәт тәрбиясе белгечлеге факультетын тәмамлый. Ульяновск сигезьеллык мәктәбендә хуҗалык мөдире һәм укытучы, райсельхозтехникада инженер-технолог, Ворошилов исемендәге колхозда машина-трактор паркы мөдире булып эшли. 1988 елда игенчелектә подряд звеносы һәм 1989 елдан аренда звеносы җитәкчесе була.

### П. А. Тимирясовның сайлау алды программасының төп нигезләре

Минем сайлау алды программамда кеше, аның ихтыяҗлары һәм интереслары, проблемалары үзәк урын тота. Шуңа да мин гуманлы, демократик социализм өчен хәлиткеч чыгыш ясыйм.

Минемчә, гуманлаштыруга бары тик хокуки дәүләт булдыру, кешенең дәүләт һәм хосусый милекчелектән тайпылуын бетерү, экономиканың бөтен авырлык үзәген кеше ихтыяҗларына буйсындыру, шәхеснең һәрьяклап үсеше өчен шартлар тудыру аркылы гына ирешү мөмкин. Ышанам: хокуки дәүләткә демократик социализмга илдә закон өстенлек итми торып, властьны законсызлык, башкару һәм судка бүлү, экономик производствоны алып баруны экономик рычагларга күчерү, кешегә гражданлык горурлыгын кайтарудан башка күчеп булмаячак.

Мин власть яклы, финанс, материаль ресурслар белән тәэмин ителгән, үз регионнарының социаль һәм экономик үсеше өчен тулы җаваплылык тоючы яңа советлар өчен. Илдә уңай үзгәрешләр мөмкинлеген дә мин Советларның тулы хокуклыгы белән бәйлим.

Экономик өлкәдә мин радикаль экономик реформа, җир, хосусыйлык, җирле үзидарә һәм экономик реформаның үзәген тәшкил итүче башка мөһим законнарны гамәлгә кертү өчен көрәшәчәкмен. Экономикада базар мөнәсәбәтләрен регулировкалауга күчү өчен дә тырышачакмын. Дәүләт бюджетының куллану өлешен киләчәктә тагын да арттыру, халык куллануы товарларын җитештерү сферасынан капиталь салулар бүлүгә, базарларны куллану товарлары белән тулыландыруга ирешәчәкмен.

Авылны төзекләндерүне үземнең гражданлык һәм киләчәктә депутатлык бурычым итеп санаячакмын. Торак пунктларын газификацияләү, аларны төзекләндерү, торак, культура-көнкүреш объектлары, юллар төзү — кичектерүне көтми торган проблемалар. Бюджет средстволарын авыл ихтыяҗлары файдасына кире бүлүгә ирешүне күздә тотам. Промышленность һәм авыл хуҗалыгы производствосы арасында тигезсез алмашуны бетерү өчен көрәшәчәкмен.

Шуның белән бергә, авылда беренче чиратта җирдә хуҗа хисен күтәрү кешенең үз язмышы хуҗасы положениесен күтәрү кирәк, дип саныйм. Шуңа да мин җиргә хосусыйлыкның күптөрле формалары өчен генә түгел, ә бәлки колхоз, аренда подразделениесендә яисә крестьян хуҗалыгында авыл хезмәтчәненең эшчәнлеген, мөстәкыйльлеген һәм хокукын арттыру өчен көрәшәчәкмен. Авылда хуҗалык итүнең барлык формалары бердәм хокуки һәм экономик шартларга куелырга тиеш.

Илдә социаль гаделлеккә, аз тәэмин ителешле гаиләләрне, балаларны, инвалидларны картларны социаль яклау өчен көрәшәчәкмен. Ышанам: җәмгыятебезнең аз тәэмин ителешле өлешенең керемнәре инфляция һәм бәяләрнең күтәрелүеннән ышанычлы сакланырга тиеш.

Мине илдә сәламәтлек саклау һәм спорт, культура һәм белем бирүнең түбән дәрәҗәдә булуы борчый. Шуңа да кешенең яшәешен тәэмин итүче бу сфералар лаеклы урын алсын өчен миңа мөмкин булган барлык средстволар белән дә көрәшәчәкмен.

Мине хатын-кызлар проблемалары, хезмәтнең авыр шартлары, кибетләрдә, поликлиникалардагы чиратлар, көнкүреш хезмәтендәге җитешсезлекләр —хатын-кызга тагын да яхшырак яшәргә, эшләргә һәм балалар тәрбияләргә комачаулык итүче бөтен нәрсә тирән борчый.

Бүгенге көндә экология иң кискен проблемалар белән беррәткә басты. Шул сәбәпле илдә әйләнә-тирәнең һәм экологиянең торышы турында тулы хәбәрдарлык һәм аңлаешлы информация буенча һәрьяклы контроль системасы булдыруны иң беренче чиратка куям. Экологик «пычрак» проектларга каршы көрәшәчәкмен.

Милли мәсьәләләр буенча, мин тулы хокуклы федерация рамкаларында политик, хокукый, экологик һәм культура ягыннан тигез хокук һәм мөстәкыйльлек бирү ягында торам.

## Елена Александровна ШӘРИФУЛЛИНА

Елена Александровна Шәрифуллина 1953 елда Куйбышев өлкәсенең Чапаев шәһәрендә туа. Милләте буенча рус. 1989 елдан КПСС члены.

1976 елда Куйбышев медицина институтын тәмамлый.

Үзенең хезмәт эшчәнлеген 1976 елның август аенда Таджикстан ССРның Курган-Түбә өлкәсендәге Калининабад шәһәр участок больницасында врач булып эшләүдән башлый.

1979 елдан Татарстанның Лениногорск шәһәрендәге балалар тудыру йортында акушер-гинеколог.

1988 елдан Лениногорск район үзәк больницасында балалык буенча баш врач урынбасары. Биредә җитәкче эшчәнлеге һәрчак врач практикасы белән янәшә үрелеп бара.

Эшләү дәверендә Е. А. Шәрифуллина үзен яхшы оештыручы, белемле һәм югары квалификацияле белгеч итеп танытты. Аның җитәкчелегендә хатын-кызларга медицина хезмәте күрсәтү яхшырды.

Ул эштә яңа формалар кертү буенча даими эш алып бара: хатын-кызларга цех принцибы буенча, ә 1984 елдан эре промышленность предприятиеләренең үзләрендә врач акушер-гинекологка турыдан-туры кабул итү мөмкинлеге булдырыла, акушерлык-терапия-педиатрия комплекслары ачыла, балалар тудыру йорты аналар һәм балаларны асрау мөмкинлегенә карап эшли, балалар больницасы бригада подрядына күчә. Е. А. Шәрифуллина кайгыртучанлыгында балалар больницасының материаль-техник базасы да ныгытыла. Ул авыл җирләрендә яшәүче балаларга һәм аналарга медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерүдә зур эш алып бара.

Иптәш Шәрифуллина медицина хезмәткәрләренең профессиональ осталыкларын күтәрү кебек мәсьәләләргә аеруча зур әһәмият бирә. Производстводан тыш ул җәмәгать эшләрендә активлык күрсәтә: күп мәртәбәләр профсоюз комитеты члены һәм аның председателе итеп сайлана. Озак еллар буена һәм бүгенге көндә дә партия мәгарифе челтәрендә пропагандист.

Ул яшьләр остазы.

Намуслы һәм тырыш хезмәте, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен Елена Александровна Шәрифуллина администрация һәм җәмәгать оешмалары тарафыннан төрле төрдәге мактауларга лаек булды.

КПССның Лениногорск шәһәр комитеты пленумы Елена Александровна Шәрифуллинаны 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтте.

### Е. А. Шәрифуллинаның сайлау алды платформасы

Мин политик реформаны тагын да тирәнәйтү, бөтен властьны Советларга кайтару аның куәтле экономик базасы һәм ресурслары булган реаль көчкә әйләндерү ягында торам.

Тормышка ашардай законнар кабул иткәндә, илнең экономикасын савыктыру, социаль мәсьәләләрне хәл итү, җәмгыятьне демократияләштерү, шулай ук совет кешеләренең сәламәтлеген ныгыту һәм саклауга юнәлдерелгән актив социаль политиканы үткәрү ягында торачакмын.

Врач буларак, сайлау алды пратформамның һәм киләчәктәге эшчәнлегемнең нигезендә экология проблемалары ятачак. «Сәламәтлек» комплекслы региональ программасының әйләнә-тирә мохитны саклауга караган өлешен тормышка ашыру, барлык оешма һәм ведомстволарның экологик халәтне яхшыртуда эшчәнлекләрен арттыру өчен тырышачакмын.

Яңа промышленность объектларын бары тик җентекләп экспертиза үткәргәннән соң гына төзи башларга кирәк дип саныйм.

Сәламәтлекне саклау һәм хатын-кызларга, балаларга медицина хезмәте күрсәтүне яхшырту социаль политиканың төп бурычларыннан берсе дип саныйм һәм түбәндәгеләр өчен тырышачакмын:

—эшче хатын-кызларның хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшырту;

—законнар актларын кабул иткәндә, хатын-кызларга производствода зарарлы һәм авыр эштә эшләргә юл куймау;

—өч яшькә кадәрге балаларны карау өчен отпускага түләүне арттыру, бу мәсьәләнең ведомство күләмендә генә түгел, ә дәүләт күләмендә каралуы;

—балалар учреждениеләренең һәм бала тудыру йортларының материаль-техник базасын ныгыту, иске дәвалау учреждениеләрен билгеләнгән срокка реконструкцияләү һәм яңаларын сафка кертү;

—мәктәп укучылары һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында авырулар саны артуга юл куймау;

—мәктәпләрнең гигиена шартларын яхшырту, авыл җирләрендә типовой проект белән мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре төзүне хәл итүдә булышлык итәчәкмен.

Укучыларны тукландыруның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итәрмен.

Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, халыкның сәламәтлеген саклау максатында кече яшьтән үк гигиена тәрбиясе, санитария-агарту, экологик яктан белем бирүгә булышлык итәчәкмен.

Милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә КПСС Үзәк Комитетының сентябрь (1989 ел) Пленумында кабул ителгән партия платформасын тулысынча хуплыйм.

Милли проблемаларны кичекмәстән, социаль, экономик һәм җәмгыятебезне демократияләштерү кебек комплекслы проблемалар белән бер үк дәрәҗәдә чишәргә кирәк дип саныйм.

